| | |
|---|---|
| **СОВЕТ НОВОМАЗИНСКОГО СЕЛЬСКОГО ПОСЕЛЕНИЯ МЕНЗЕЛИНСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН** | **ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ МИНЗӘЛӘ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНА ЯҢА МАҖЫН АВЫЛ ҖИРЛЕГЕ СОВЕТЫ** |

**РЕШЕНИЕ** **КАРАР**

**№3** **«14» ноября 2021 ел**

**Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Яңа Мажын авыл җирлеге составына керүче Яңа Мажын торак пунктында халык җыены нәтиҗәләре турында**

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 6 октябрендәге №131-ФЗ Федераль законның 25.1, 56 статьялары, «Татарстан Республикасында җирле үзидарә турында» 2004 елның 28 июлендәге №45-ТРЗ Татарстан Республикасы Законының 35 статьясы нигезендә гражданнар җыены нәтиҗәләре буенча 14.11.2021 елда үткәрелгән халык җыены нәтиҗәләре буенча беркетмә төзелде:"2022 елда үзара салым кертүгә Сез Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Яңа Мажын авыл җирлегенең Яңа Мажын торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешедән 500 сум күләмендә акча кертүгә килешәсезме, түбәндәгеләрдәнтыш: көндезге уку формасы буенча укучы студентлар, I төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләр, һәм алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү:

- Яңа Мажын торак пунктында су башнясы территориясен төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу, койма урнаштыру, скважина янында чокырларга грунт салу, килешү буенча эшләр өчен түләү).
- Яңа Мажын торак пунктында Молодежная урамы буенча авыл эчендәге юлларны ремонтлау (төяү, ташу, ком ташын , ком-гравий катнашмасын җәю, килешү буенча түләү).

Халык җыены нәтиҗәләре турында беркетмә нигезендә:
сайлау хокукына ия җыенда катнашучылар исемлегенә кертелде 200 җыенда катнашучылар, тавыш бирүдә катнашкан гражданнар җыенында катнашучылар саны 129 кеше.

Тавыш бирү нәтиҗәләре буенча гражданнар җыенында катнашучыларның тавышлары түбәндәгечә бүленде:
"РИЗА" позициясе өчен тавыш бирде 129 халык җыенында катнашучылар;

"КАРШЫ" позициясе өчен тавыш бирде 0 җыенда катнашучылар.

Бәян ителгәннәр нигезендә, халык җыены карар чыгарды:

1. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Яңа Мажын авыл җирлегенең Яңа Мажын авыл җирлегендә халык җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә дип танырга.

2. Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Яңа Мажын авыл җирлегенең Яңа Мажын торак пунктында халык җыены булып узды, халык җыены нәтиҗәләре гамәлдә, дип танырга. Минзәлә муниципаль районы Яңа Мажын авыл җирлеге Яңа Мажын торак пункты территориясендә яшәү урыны буенча теркәлгән һәр балигъ булган һәр кешегә 2022 елда үзара салым кертергә 500 сум күләмендә килешәсезме?: көндезге уку формасы буенча укучы студентлар, I төркем инвалидлар, Бөек Ватан сугышында катнашучылар, Бөек Ватан сугышында катнашучыларның тол хатыннары, Россия Армиясе сафларында хезмәт итүчеләрдән башка, - алынган акчаларны түбәндәге эшләрне башкару буенча җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүгә җибәрү:

- Яңа Мажын торак пунктында су башнясы территориясен төзекләндерү (төзелеш материаллары сатып алу, койма урнаштыру, скважина янында чокырларга грунт салу, килешү буенча эшләр өчен түләү).

- Яңа Мажын торак пунктында Молодежная урамы буенча авыл эчендәге юлларны ремонтлау (төяү, ташу, ком ташын , ком-гравий катнашмасын җәю, килешү буенча түләү).

3. Җыенның нәтиҗәләрен Яңа Мажын авыл җирлеге Советының мәгълүмати стендларында, Татарстан Республикасы Муниципаль берәмлекләре порталы составында Минзәлә муниципаль районы сайтында урнаштыру юлы белән халыкка игълан итәргә http://menselinsk.tatarstan.ru Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында http://pravo.tatarstan.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Муниципаль норматив хокукый актлары Регистрына кертү өчен Татарстан Республикасы Минзәлә муниципаль районы Яңа Мажын авыл җирлеге башлыгына җибәрергә

Халык җыенында рәислек итүче,
ТР Минзәлә муниципаль районы
Яңа Мажын авыл җирлеге башлыгы И. А. Колбин